Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының
Ислəй авыл җирлегенең Ислəй авылындагы
гражданнар җыены

КАРАР

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Ислəй авыл җирлеге составына керүче Ислəй авылындагы гражданнар җыены нəтиҗəлəре турында

2020 елның 20 ноябре №1

«Россия Федерациясендə җирле үзидарə оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарə турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендə, «2021 елда Чистай муниципаль районының Ислəй авыл җирлегенең Ислəй авылы территориясендə яшəү урыны буенча теркəлгəн һəр балигъ булган кешедəн, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, 1 төркем инвалидларыннан тыш, 500 сум күлəмендə үзара салым кертүгə һəм җирле əһəмияттəге мəсьəлəлəрне хəл итүгə алынган акчаларны түбəндəге эшлəрне башкаруга җибəрү белəн ризалашасызмы?» дигəн сорау буенча 2020 елның 20 ноябрендə узган гражданнар җыены нəтиҗəлəре белəн гражданнар җыены беркетмəсе төзелде:

- авыл эчендəге юлларны ремонтлау һəм карап тоту (вак таш сатып алу һəм китерү, грунт салу һəм гредированиелəү, вак таш салу, юлларны тигезлəү, чокырлы юлларны ремонтлау, кар чистарту, килешүлəр буенча түлəү)

« РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нəтиҗəлəре турындагы беркетмə нигезендə:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенə гражданнар җыенында 158 катнашучы кертелгəн, җыенда катнашучылар саны 129 кеше.

Тавыш бирү нəтиҗəлəре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбəндəгечə бүленде:

**«**РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенының 129 катнашучысы тавыш бирде;

**«**КАРШЫ» позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бəян ителгəннəр нигезендə гражданнар җыены карар итте:

1. Чистай муниципаль районының Ислəй авыл җирлегенең Ислəй авылындагы гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нəтиҗəлəрен - дөрес дип танырга.

2. «2021 елда Чистай муниципаль районының Ислəй авыл җирлегенең Ислəй авылы территориясендə яшəү урыны буенча теркəлгəн һəр балигъ булган кешедəн, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, 1 төркем инвалидларыннан тыш, 500 сум күлəмендə үзара салым кертүгə һəм җирле əһəмияттəге мəсьəлəлəрне хəл итүгə алынган акчаларны түбəндəге эшлəрне башкаруга җибəрү белəн ризалашасызмы?» дигəн сорау буенча карарны кабул ителгəн дип танырга:

- авыл эчендəге юлларны ремонтлау һəм карап тоту (вак таш сатып алу һəм китерү, грунт салу һəм гредированиелəү, вак таш салу, юлларны тигезлəү, чокырлы юлларны ремонтлау, кар чистарту, килешүлəр буенча түлəү)».

3. Чистай муниципаль районының Ислəй авыл җирлегенең Ислəй авылы территориясендə 2021 елда үзара салымны, Чистай муниципаль районының Ислəй авыл җирлегенең Ислəй авылы территориясендə яшəү урыны буенча теркəлгəн һəр балигъ

булган кешедән, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, 1 төркем инвалидларыннан тыш, 500 сум күләмендә кертергә, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту (вак таш сатып алу һәм китерү, грунт салу һәм гредированиеләү, вак таш салу, юлларны тигезләү, чокырлы юлларны ремонтлау, кар чистарту, килешүләр буенча түләү).

4. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләрне күпләп җыелган урыннарда, игълан итү стендларында һәм такталарында элеп чыгу юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Исләй авыл җирлеге
башлыгы _________________ В.П.Чернышев